Төзекләндерү

# ҖӘЯҮЛЕЛӘР ЮЛЫ, ЯЛ ИТҮ УРЫНЫ, ФОНТАН ДА КИРӘК

Соңгы ике ел эчендә шәһәрдә барган үзгәрешләрне күрмәгән кеше юктыр. Мәсәлән, Кара елганың элек нинди халәттә булганын бүген инде күз алдына китерү дә авыр. Яхшылыкка, матурлыкка тиз ияләнәбез шул. Кайчандыр чүп-чарга батып яткан елга буенда бүген вәзгыять бөтенләй башка: биредә спорт белән шөгыльләнергә, балалар белән рәхәтләнеп ял итәргә була. Бөтен җир яктыртылган, күз явын алырдай күперләр ясалган.



Җиңү, Гаилә паркларындагы зәвык белән эшләнгән кече архитектура формалары, чәчәк түтәлләре, декоратив агачлар, яшеллек, җәяүлеләр, велосипедчылар һәм шулай ук физик кимчелекле кешеләр өчен дә уңайлы итеп ясалган юллар ... ерактан үзенә дәшеп, уңайлы ял шартлары тудыра.

Әлеге киң масштаблы эшләрнең барсы да республика программаларына нигезләнеп башкарылды. Ул вакытта "Инде шәһәрдә үзгәртерлек урыннар да калмады", – диючеләр дә аз булмады.

Быел исә, иҗтимагый киңлекләр елында, шәһәрдә тагын да зуррак эшләр башкару күздә тотыла: Нефтьчеләр урамы капиталь ремонт кичереп, тулысынча төзекләндерелачәк. Әлеге урамны Азнакай халкы нинди итеп күрә? Анда нинди объектлар, уңайлыклар булырга тиеш? Узган атнада Мәдәни үзәктә оештырылган очрашуда теләге булган һәркем катнашып, үз теләк-фикерен белдерә алды. Биредә Казан белгечләре – проектчылар, архитекторлар да катнашты.

Мәдәни үзәк залында бу көнне алма төшәр урын да булмады дисәң дә хилафлыкка туры килмәс, мөгаен! Фикер алышучылар арасында яшьләр активистлары, укучылар, укытучылар, социаль өлкә, мәдәният тармагы вәкилләре, нефтьчеләр, табиблар, җәмәгать эшлеклеләре, коммуналь-хуҗалык тармагы вәкилләре... һәм тагын бик күпләр бар иде.

– Әшкә керешкәнче, башта халык фикерен беләсебез килгән иде, – ди команда модераторы Айрат Фәйзрахманов. – Чөнки мондагы территорияне ничек матуррак итәргә кирәклеген сездән дә яхшырак белүче юк: сез биредә яшисез, шул уңайлыклардан файдаланасыз.

Нефтьчеләр урамы – үзәк урамнарның берсе, шуңа аны төзекләндерү беркемне дә битараф калдырмады, әлбәттә. Әле эш моның белән генә бетмәячәк, киләсе елда Хәсәншина урамы да үзгәреш кичерер дип көтелә.

Башта Казан кунаклары алдагы елларда Җиңү һәм Гаилә парклары, Кара елга буенда барган төзекләндерү эшләре буенча азнакайлыларның фикерен тыңлады.

– Бөтен җир матур, ләкин паркта мәгълүмати стендлар юк, – ди торак-коммуналь хуҗалыгы һәм төзекләндерү департаменты җитәкчесе Руслан Мөгътәсимов. – Аерым урыннарда ветераннарыбыз, Бөек Ватан сугышындагы төрле алышлар турында тулырак мәгълүмат булса, яшьләребез генә түгел, өлкәннәр дә зур кызыксыну белән танышыр иде.

Әлеге һәм башка фикерләрне дә язып алды проект төзүчеләр. Алга таба алар Нефтьчеләр һәм Хәсәншина урамнарында булган проблемалар белән дә танышты.

Биредә җәяүлеләр чыга торган урыннарның караңгы булуыннан, яңгырлы көннәрдә, яз-көз айларында аерым урыннарда су җыелып торудан, тротуарларның уңайсыз, урам чатларының – хәвефсезлек кагыйдәләренә туры килмәвеннән, агачларның аз булуыннан зарланучылар байтак булды.

Соңыннан азнакайлылар төркемнәргә бүленеп, Нефтьчеләр һәм Хәсәншина урамнарын төзекләндерү буенча үз эскиз проектларын төзеде һәм аларны башкаларга тәкъдим итте.

Әйе, теләкләр байтак булды. Берәүләр агачларны күбрәк утыртырга кирәк дисә, коммунальчылар исә Нефтьчеләр урамына агачлар утырту белән килешмәде: кыш көннәрендә әлеге территорияне кардан чистартканда сынып бетәчәк диган фикердә алар. Аннан урындыклар куйган очракта да, аларны торак йортлардан читкәрәк куярга кирәк дигән фикерне дә җиткерделәр.

– Төннәрен җыелып сөйләшә башласалар, йортларда яшәүчеләргә уңайсызлыклар гына тудырачаклар, – ди алар.

Торак-коммуналь хуҗалык тармагы вәкилләре Нефтьчеләр-Ленин урамы чатын киңәйтү яклы.

– Чат почмакларына нефтьчеләр, авыл хуҗалыгына багышланган архитектура формалары да урнаштырылсын иде, – ди төркем исеменнән чыгыш ясаган Руслан Мөгътәсимов.

Яшьләр – яшел диган гыйбарәне инде күптән кулланылыштан төшереп калдырырга вакыт. Аларның уй-теләкләрен тыңлаганда әнә шундый фикер туды. Ник дигәндә, яшьләребез "кирәк" принцибыннан чыгып кына фикер йөртми. Барсы да уйланган һәм төгәл.

– Федераль казна бинасы каршын матурларга иде. Архитектура объектлары куеп, чәчәкләр утыртсаң, нинди күңелле булачак. Аннан берничә җирдә туңдырма сату урыны да кирәк, – ди яшьләр үзәге белгече Илдар Нәгыймов.

Яшьләр фотога төшәр өчен махсус фотозона да кирәк дип исәпли.

Күпчелекнең исә фикере уртак булды: ял итүчеләр өчен утыргычлар, яктырткычлар, чүп ташлау өчен махсус кәрҗиннәрне күбрәк итәргә кирәк, велосипед, җәяүлеләр юллары, бушлай wi-fi зона, балалар бакчаларына килгән машиналарга туктау өчен урыннар... Арада скандинавия йөреше өчен махсус юл кирәк диган фикер дә яңгырады.

– Нефтьчеләр урамы – үзәк урамнарыбызның берсе, шуңа аны яшеллеккә төренгән, барлык уңайлыклары булган, зәвыклы урын итеп күрәсе килә ди, – электр челтәрләре предприятиесе җитәкчесе Айдар Шәрәфиев.

Ул "Чатыр-Тау Арена" спорткомплексы тирәсенә кечкенә генә булса да фонтан куеп булмас микән диган фикерне дә җиткерде.

Кыскасы, фикерләрнең ниндие генә яңгырамады бу көнне! Архитекторлар аларның барсын да исәпкә алырга вәгъдә бирде.

– Биредә туган ягының язмышына, аның киләчәгенә битараф булмаган кешеләрнең күп булуы сөендерә. Бу кадәр актив, "яньп" торган кешеләрне әле бер генә районшәһәрдә дә күргән булмады, – ди проект авторы, архитектор Илдар Мирхазиянов.

– Матурлык дөньяны коткарыр дип юкка әйтмиләр. Яшәгән җиребез матур икән, кәефебез дә яхшы булачак, – диде чараны йомгаклап район башкарма комитеты җитәкчесе Айдар Шәмсетдинов. – Һәркем мондый зур эшләрне башкару өчен күп акчалар кирәклеген дә яхшы аңлый. Программа кысаларында республика бюджетыннан 30 миллион сум акча каралган. Биредә нефтьчеләребезнең ярдәменә дә ышанып калабыз.

Шунысы мәгълүм, проект авторлары яшелләндерүгә аеруча өстенлек бирәчәкләр.

–Без һәркемне тыңларга әзер, – ди алар.

Бу көнне чарада катнаша алмаганнар үз тәкъдим-фикерләрен язма рәвештә дә белдерә ала. Хатларны info@tatar.ru адресына гына юлларга кирәк.

Әйдәгез, торган җиребезне матурлап, уңайлы итүдә үз өлешебезне кертик!

**Таңсылу САНИЕВА**

МЧС кисәтә

# ЯЗГЫ ТАШУ ҺӘМ АҢА НИНДИ ӘЗЕРЛЕКТӘ ТОРЫРГА

Синоптиклар быел язгы ташу көчле булыр дип фаразлыйлар. Моңа язның иртә килүе дә йогынты ясарга мөмкин. Кисәтелгән, димәк коралланган, диләр. Мондый очракта ниләр эшләргә кирәклекне белеп тору бер дә зыян итмәс.

Ташу сулары йортларга якын килсә, электр үткәргечне өзәргә, газны сүндерергә, тәрәзәләрне капларга кирәк. Салкын суга кергәнче әзерләнү мөкинлеге булса, запас кием-салым, кайнар эчемлек әзерләгез. Чалбар балагы, күлмәк җиңнәренә туп, шар, буш пластмасс шешәләр тутыру ышанычлы. Әгәр инде су эчендә калсаң, авыр киемне, аяк киемнәрен салып, берәр әйбергә ябышып, ярдәм көтеп агым буенча йөзәргә кирәк. Кеше суда әгәр аның температурасы 7-8 градус булса – 3-4, ә 3-4 градус булса, 1,5-2 сәгать тора ала. Әчтән паникага бирелмәскә, кискен хәрәкәтләр ясамаска кирәк. 40-60 процент җылы кешенең башы аша уза, шуңа да юеш булса да баш киемен салмагыз! Очлы, үткен бозлардан сак булыгыз! Онытмагыз, кешеләр суда еш кына салкыннан түгел, күп кан югалтудан һәлак булалар. Юка боз өстенә чыгудан файда юк. Иң яхшысы аны сак кына ватып, акрын-акрын алга барырга. Ярга чыккач, киемнәрне сыгарга, җылыткыч күнегүләр ясарга кирәк, йоклап китүдән сак булыгыз. Озак вакыт салкын суда торган кешегә беркайчан да спиртлы эчемлекләр бирмәгез! Бу киресенчә кешене һәлак итәргә мөмкин. Спирт белән тәнне ышкуның да нәтиҗәсе юк. Мөмкин булганча аны коры киемгә киендерергә тырышыгыз һәм аяк-кулларга массаж ясый башларга кирәк.

***Йортыгызны су баскан икән, бинага җимерелеп төшү куркынычы булмаганда гына керегез, электр утларын кабызмагыз, ачык уттан файдаланмагыз, чөнки газ челтәре, электрүткәргечләргә зыян килгән булырга, җыелган газ шартларга мөмкин.***

Иң әһәмиятлесе: каушап калмаска! Мал-туар, кече дусларыбызның иминлеге хакында да онытмыйк! Аларны бинадан чыгарырга, этләрне бәйдән ычкындырырга кирәк.

